| | |
|---|---|
| **Совет Большеачасырского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлеге Советы** |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 4 сентябрь 2020 ел | №255 |

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча аерым вәкаләтләрен тапшыру турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы "Олы Ачасыр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1.Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге җирле үзидарә органы белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең үз матди ресурслары һәм финанс чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**